**Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының**
**Бураково авыл җирлеге**
**Советы**

# К А Р А Р

№ 150 17.06.2025 ел

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Бураково авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 3, 7 пунктлары, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 6 статьясындагы 2 өлеше, 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Бураково авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Бураково авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының бишенче чакырылыш Бураково авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советы депутатларын сайлауларны 2025 елның 14 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны рәсми рәвештә 2025 елның 20 июнендә «Яңа тормыш» газетасында һәм Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында - http://spasskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында - http://pravo.tatarstan.ru, кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча, халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның рәсми игълан ителгәннән соң үз көченә керүен билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Спас муниципаль районының
Бураково авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Мингалиев